Республика Татарстан
СОВЕТ КИЛЬДЕБЯКСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
САБИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
, Республика Татарстан,
с. Кильдебяк, ул. Кооперативная, 20а
тел. 45-5-50

Татарстан Республикас
САБА МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ
КИЛДЕБЭК АВЫЛ ЖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ
, Татарстан Республикасы,
Килдебәк авылы, Кооперати
урамы, 20а йорт
тел. 45-5-50

e-mail: Kilb.Sab@tatar.ru

19 сентябрь 2020 ел

№ 9

# КАРАР

Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Килдебәк авыл җирлеге Советының 2019 нчы елның 2 нче июлендәге 13 нче номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Килдебәк авыл җирлеге территориясендә гражданнар арасында сораштыру билгеләү һәм үткәрү тәртибе турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында» 20.07.2020 ел, № 236-ФЗ Федераль закон нигезендә, Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Килдебәк авыл җирлеге Советы

Карар кылды:

1. Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Килдебәк авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Килдебәкавыл җирлеге территориясендә гражданнар арасында сораштыру билгеләү һәм үткәрү тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2019 елның 2 июлендәге 13 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Килдебәк авыл җирлеге территориясендә гражданнар арасында сораштыру билгеләү һәм үткәрү тәртибе турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1.1 пунктка түбәндәге эчтәлекле тәкъдим өстәргә: "гражданнарның инициативалы проектка ярдәм итү турындагы фикерен ачыклау мәсьәләсе буенча үткәрелгән сораштыруда инициативалы проектны гамәлгә ашыру тәкъдим ителүче муниципаль берәмлек яки аның өлешендә яшәүче уналты яшькә җиткән гражданнар катнашырга хокуклы.

2. Әлеге карарны "Интернет" мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru, Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Килдебәкавыл җирлегенең рәсми сайтында: http://saby.tatarstan.ru/kildebiak адресы буенча, җирлекнең мәгълүмати стендларында бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карар 01.01.2021 үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Авыл җирлеге башлыгы Н.Н.Заһидуллин